**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 23 сентябрь № 681

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 22 апрель, 267 нче; 2014 ел, 1 октябрь, 708 нче; 2014 ел, 14 ноябрь, 876 нчы; 2014 ел, 12 декабрь, 977 нче; 2015 ел, 8 апрель, 231 нче; 2015 ел, 19 май, 358 нче; 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы; 2015 ел, 16 июнь, 442 нче; 2015 ел, 2 ноябрь, 831 нче; 2016 ел, 24 февраль, 112 нче; 2016 ел, 15 апрель, 225 нче; 2016 ел, 8 май, 288 нче; 2016 ел, 22 июнь, 498 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны | Программаны финанслауның гомуми күләме 172 233 865,484 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 128 053 288,418 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 44 127 915,6 мең сум, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия исәбеннән – 31 484,4 мең |

| | |
|---|---|
| финанслау күләмнәре | сум, бюджеттан тыш чыганаклардан (Тормыш хәле авыр булган балаларга ярдәм күрсәтү фондыннан алынган акча) –21 177,066 мең сум, шулардан 1 654,537 мең сум – 2013 елда алынган тотылмый калган акча: |

(мең сум)

| Ел | Финанслау күләме – барлыгы | Шул исәптән | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | федераль бюджет акчасы | Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия | бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2014 | 20 908 005,515 | 15 441 582,078 | 5 450 597,7 | 14 171,2 | 1 654,537 |
| 2015 | 22 567 805,0 | 16 347 332,0 | 6 209 073,9 | 11 399,1 | - |
| 2016 | 25 268 153,706 | 19 143 697,14 | 6 108 858,11 | 5 914,1 | 9 684,366 |
| 2017 | 24 337 702,063 | 18 132 505,8 | 6 195 358,1 | - | 9 838,163 |
| 2018 | 25 369 288,7 | 18 907 530,2 | 6 461 758,5 | - | - |
| 2019 | 26 404 974,0 | 19 678 283,1 | 6 726 690,9 | - | - |
| 2020 | 27 377 936,5 | 20 402 358,1 | 6 975 578,4 | - | - |
| Барлыгы | 172 233 865,484 | 128 053 288,418 | 44 127 915,6 | 31 484,4 | 21 177,066 |

Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 172 233 865,484 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 128 053 288,418 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 44 127 915,6 мең сум, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия исәбеннән – 31 484,4 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан (Тормыш хәле авыр булган балаларга ярдәм күрсәтү фондыннан алынган акча) – 21 177,066 мең сум, шулардан 1 654,537 мең сум – 2013 елда алынган тотылмый калган акча:

(мең сум)

| Ел | Финанслау күләме – барлыгы | Шул исәптән | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | федераль бюджет акчасы | Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия | бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2014 | 20 908 005,515 | 15 441 582,078 | 5 450 597,7 | 14 171,2 | 1 654,537 |
| 2015 | 22 567 805,0 | 16 347 332,0 | 6 209 073,9 | 11 399,1 | - |
| 2016 | 25 268 153,706 | 19 143 697,14 | 6 108 858,11 | 5 914,1 | 9 684,366 |
| 2017 | 24 337 702,063 | 18 132 505,8 | 6 195 358,1 | - | 9 838,163 |
| 2018 | 25 369 288,7 | 18 907 530,2 | 6 461 758,5 | - | - |
| 2019 | 26 404 974,0 | 19 678 283,1 | 6 726 690,9 | - | - |
| 2020 | 27 377 936,5 | 20 402 358,1 | 6 975 578,4 | - | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Бар-лыгы | 172 233 865,484 | 128 053 288,418 | 44 127 915,6 | 31 484,4 | 21 177,066 |

Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Программаны ресурслар белән тәэмин итү буенча җентекле мәгълүмат әлеге Программага теркәлгән 2 нче кушымтада китерелә.»;

Программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм аларны капиталь ремонтлау» ярдәмче программасында (алга таба – ярдәмче программа):

ярдәмче программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программа исеме | «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм аларны капиталь ремонтлау» ярдәмче программасында (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| Төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерцияле булмаган оешмасы |
| Ярдәмче программа максаты | Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә гражданнарның тереклек эшчәнлеге өчен уңайлы һәм имин шартлар тудыру |
| Ярдәмче программа бурычлары | Социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә капиталь ремонтның дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрүне тәэмин итү һәм санитария-эпидемиология нормаларын һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләрен саклау |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2015 – 2020 еллар |
| Еллар һәм чыганаклары буенча бүлеп, ярдәмче программаны финанслау | Татарстан Республикасы бюджетыннан программаны финанслауның гомуми күләме 1 651 163,2 мең сум тәшкил итә, шул исәптән: |

<table>
<tr><td>күләмнәре</td><td><table><tr><td>Ел</td><td>Финанслау күләме – барлыгы</td></tr><tr><td>2015</td><td>318 793,20</td></tr><tr><td>2016</td><td>1 332 370,0</td></tr></table>Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш</td></tr>
<tr><td>Еллар буенча бүлеп, ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)</td><td>Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкән яшьтәге гражданнарга, инвалидларга (өлкәннәр һәм балалар), билгеле бер яшәү һәм эш урыны булмаган затларга социаль хезмәт күрсәтүнең стационар учреждениеләре биналарының гомуми санында өлкән яшьтәге гражданнарга, инвалидларга (өлкәннәр һәм балалар), билгеле бер яшәү һәм эш урыны булмаган затларга социаль хезмәт күрсәтүнең стационар учреждениеләренең төзекләндерү таләп ителгән, авария хәлендә булган тузган биналарының чагыштырма авырлыгын нульгә тигезләүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.»;</td></tr>
</table>

Ярдәмче программаның II бүлегендәге бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары: 2015 – 2020 еллар.»;

Ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Татарстан Республикасы бюджетыннан Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1 651 163,2 мең сум тәшкил итә, шул исәптән 2015 елда – 318 793,20 мең сум, 2016 елда – 1 332 370,0 мең сум.

Ярдәмче программа чараларын финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының җыелма сметасы кысаларында гамәлгә ашырыла. Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.»;

Ярдәмче программаның IV бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмнары

Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы – Ярдәмче программаның координаторы булып Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тора. Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары һәм анда каралган ассигнованиеләр белән төп эш итүчеләр – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы.

Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыруда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы карамагындагы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре катнаша.

Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары һәм чараларын үтәүчеләр түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

чараларны үтәү барышын тикшерүдә тоту;

бүлеп бирелә торган финанс чараларын үтәүчеләр тарафыннан рациональ файдалануны тикшерүдә тоту;

Ярдәмче программа чаралары кисемендә узган чорга (квартал, ел) Ярдәмче программаны үтәү турында хисаплар формалаштыру;

Ярдәмче программаны тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган финанс чараларын исәпкә алып, Ярдәмче программа чаралары буенча максатчан күрсәткечләрне һәм чыгымнарны, Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмын һәм аның үтәүчеләр составын тәгаенләү.

Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15енә кадәр Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Ярдәмче программаны тормышка ашыру турында шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә (алга таба – Тәртип) 5 нче кушымта нигезендә форманы тутырып, финанс чараларын куллану нәтиҗәлелеге турында статистик, мәгълүмати һәм аналитик мәгълүматны тапшыра.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 25енә кадәр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы кысаларында Ярдәмче программаны тормышка ашыру, шулай ук Тәртипкә 5 нче кушымта нигезендә форманы тутырып, финанс чараларын куллану нәтиҗәлелеге турында статистик, мәгълүмати һәм аналитик мәгълүматны тапшыра.»;

Ярдәмче программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлде).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\681.docx